**Казан шәһәре Совет районы МАББУ “100нче татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш төрдәге балалар бакчасы ”**

**ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ**

**ТЕМА:**

# “Музей педагогикасы”

Проект авторы:
Якупова Алсу Наиловна
югары категорияле тәрбияче
Мәктәпкә әзерлек төркеме

Казан.

**Эчтәлек**

1.Аңлатма язуы -----------------------------------------------------------------------
2 Iэтап. Әзерләнү ----------------------------------------------------------------------
3.II этап.Белем бирү өлкәсе ----------------------------------------------------------
4. III этап. Нәтиҗә ---------------------------------------------------------------------
5.Кушымта -------------------------------------------------------------------------------
6.Кулланылган әдәбият -------------------------------------------------------------

**Аңлатма язуы:** проект 5-6 яшьлек балаларга ел дәвамында туган як тарихы тормыш – көнкүреше турында билгеле күләмдә гомуми башлангыч белем бирү белән бергә чын кешелек хисләрен уятуны, аны акыллы шәхес итеп тәрбиялүне күз алдында тота. Дәвамлы проект буларак , алга таба балаларны туган халкының тарихын, милләт тарихын, туган җир, туган ил халыклары тарихын өйрәнү аша дөнья тарихын да кабул итә, өйрәнә, таный ала торган, алга омтылучы, камил, толерант шәхес итеп тәрбиялүне, үстерүне күз алдында тота.

**Максат:** Мәктәпкә эзерлек төркемендә туган шәһәр, үзләре яшәгән социаль тирәлек, туган якның тарихын, җирлеген, горыф гадәтләрен өйрәү аша башка халыкларның, туган илнең үсешен өйрәне, алга таба аның үсешенә өлеш кертә алырлык шәхес тәрбияләргә башлангыч адымнарны ясау.

**Бурычлар:**

- туган шәһәр, үзләре яшәгән социаль тирәлек туган якның тарихын, җирлеген, өйрәтү;
- тәҗрибә,эзләнүләргә теләк, кызыксыну тудыру;
- электр турында башлангыч белемнәрен ныгыту;
- булган белемгә таянып яңа мәгълүмат бирү;
- үзеңне кызыксындырган мәгълүмат алу теләген үстерү;
- бергәләшеп, аралашып эшли белү үрнәген тәрбияләү.

Белем бирү өлкәләрендә:

**Танып – белү үсеше -** балаларга туган як тарихы турында тарихлар сөйләү, аларның электр, электр җиһазлары турындагы белемнәрен үстерү, аларның кулланышта торган урыны, кирәклеге турында яңа мәгълумәт бирү, эзләнүләргә кызыксыну тәрбияләү.

**Сөйләм теле үсеше -** балаларның телен яңа сүзләр белән баету, аларны фикерләгәндә, җөмлә төзелешендә куллана белергә өйрәтү.

**Социаль - шәхси үсеш** – электр җиһазларын кулланганда куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту, ярдәмләшеп эшии белергә өйрәтү.
**Нәфис – нәфәсәти үсеш-** туган шәһәр турында булган белемнәрен нәтиҗәле эшчәнлектә куллана белү

**Проектның төре:** Дәвамлы проект.
Танып белү,социаль тирәлекне өйрәнү, тел байлыгын үстерү,эзләнүләр.
**Катнашучылар:** төркем балалары 5 -6 яшь, тәрбияче, ата-аналар.
**Үткәрү вакыты:** сентябрь- май
**Күзәтү өлкәсе:** көнкүрештә, урамда, җәмәгать урыннарында, музейларда күзәтүләр, экскурсияләр үткәрү.
**Финанс чыганаклары:** шефлык ярдәме белән.

**Проект этаплары:**
**1 этап. Әзерләнү .**
**1.** Белем һәм тәрбия бирү программалары, методик кулланмалар туплау:
1.”Сөенеч.Радость познания”
Балаларның тормыш куркынычсызлыгы турында белемнәрен ныгытуда матур әдәбият үрнәкләре (Автор Закирова К.В.,Казан “Хәтер”, 2011)
2. Дыбина О.В.Ознакомление с предметным и социальным окружением.5-6 .М.: М-Синтез, 2017.

2. Чәчмә һәм күрсәтмә әсбаблар туплау:
-электр барлыкка килгәнгә кадәр аларны алыштырган җихазлартуплау.Кушымта 1
- презентация: “Казан- электр утына кадәр”, “Казанда электр тарихы” . Кушымта 2
-иллюстрацияләр җыелмасы: “Көнкүреш техникасы”, “Детям о бытовых приборах”.Кушымта 3
- тәрбиячеләр өчен электр челтәре турында белешмә бирүче китаплар: “КЭС на рубеже веков” Казань, 2010, “ Традиции, инновации и надежность на во благо столицы”, Казань, Татэнерго.2018.
- видеоматериаллар:
- Фиксиклар. Мультфильмнар. Казан.Татарстан республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2012;

- : күрсәтмә – дидактик әсбаблар: “Расскажите детям о бытовых приборах”.М., “МОЗАИКА - СИНТЕЗ”, 2011;

-“Бытовая техника”. Ростов на Дону, “Проф-Пресс”, 2016.

3. Интерактив, дидактик уеннар:

“Иске- яңа җихазлар”

“Ярый- ярамый”

“Нәрсә беренче булган”.

4.“Казанда – электр тарихы” балалар бакчасының музеен ачу.

5. Тәрбиячегә башка педагоглар,социаль тирәлек белән аралашып эшләү.

6. Балалар белән эш формалары туплау.

**II этап. Белем бирү өлкәсе**

**Эш процессында кулланыла торган чаралар:**

- Интернеттан Бала.ру, “Дошкольное воспитание” сайтлары аша электр турында, яшь үзенчәлегеннән чыгып, темага кагылышлы документаль фильмнар, мультфильмнар карау;
- Туган шәһәр белән танышканда сөйләм телен үстерү буенча хикәяләр төзү; дидактик уеннары ясау;
- Туган шәһәрнең тарихын, горыф - гадәтләрен даими рәвештә өйрәнү, күзәтү, экскурсияләр оештыру.

**Проектны балалар белән эштә тормышка ашыру:**

| **ай** | **атн** | **Тема** | **Эшчәнлек** | **Белем бирү** | **Методик алымнар** |
|---|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | | Туган шәһәрем- Казан. | Туган тел, Тирәлек белән таныштыру | Танып-белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Электр уты турында әңгәмә, презентация карау, экранда рәсемнәр карау, проблемалы ситуацияләр чишү, күзәтү. |
| Октябрь | 1 | Электр уты барлыкка килгәнче-Казан | Туган тел, Тирәлек белән таныштыру | Танып белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Презентация карау, дидактик уен “Көнкүреш техникасы” |
| Ноябрь | **1** | Электр утына кадәр аны алыштырган җихазлар– хуҗалык кирәк ярагы | Туган тел, Тирәлек белән таныштыру | Танып белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Экранда фильм карау,фотография, күзәтү, куллану. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| декабрь | **1** | Электр тогы һәм аннан саклану чаралары | Туган тел, Тирәлек белән таныштыру | Танып белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Экранда рәсемнәр, видеоязма карау, презентация карау, күргән буенча сөйләү. |
| Январь | **1** | “Казанда – электр тарихы”- музей ачу | Тирәлек белән таныштыру | Танып белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Экспонатлар белән таныштыру, тарихи белем бирү |
| Февраль | **1** | Кер үтүкләү җихазлары, куллану | Эксперементл ар. | Танып белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Эксперемент ясау, Стенд янында сөйләшү,экранда рәсемнәр карау, |
| Март | **1** | Яктырту чаралары: Элек-хәзер. | Дидактик уен. Әңгәмә | Танып белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | Экранда рәсемнәр карау, табышмаклар чишү. |
| апре | **1** | Музейга сәяхәт | Экскурсия | Танып/Нәфәсәти тәрбия | |
| май | **1** | Электр җиһазлары- кулланышта | Рәсем ясау | Нәфәсәти тәрбия | |

**III этап. Күтелгән нәтиҗә.**

1. Балаларның шәһәр электр тарихы турында, яшь үзенчәлегеннән чыгып, мәгълүмат алу.
2. Шефлык эше, ата – аналар, педагоглар ярдәмендә музейны яңа экспонатлар белән тулылындыру.
3. Стендлар ясау:“Казан- электр утына кадәр”, “Казанда электр тарихы”.
4. Ата – аналар, балалар белән рәсем күргәзмәсе оештыру .
5. Эш тәҗрибәсен шәһәр, район методик берләшмәләрендә, “Мирас” семинары, республика белем күтәрү курслары курсантларына тәкъдим итү.
6. Алып барган эшне балалар бакчасы сайтында чагылдыру.
7. Эш тәҗрибәсен “Мәгариф” фәнни- методик журналда бастыру.

Кулланылган әдәбият:

1. Балаларның тормыш куркынычсызлыгы турында белемнәрен ныгытуда матур әдәбият үрнәкләре (Автор Закирова К.В.,Казан “Хәтер”, 2011)

2. Дыбина О.В.Ознакомление с предметным и социальным окружением.5-6 .М.: М-Синтез, 2017
3.“КЭС на рубеже веков” Казань, 2010,

4.“Традиции, инновации и надежность на во благо столицы”, Казань, 2018.,(Татэнерго нәшерендә).